| | | |
|---|---|---|
| МИНИСТЕРСТВО<br>ЛЕСНОГО ХОЗЯЙСТВА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>УРМАН ХУҖАЛЫГЫ<br>МИНИСТРЛЫГЫ |

ПРИКАЗ　　　　　　　　　　БОЕРЫК

23.04.2019　　　　　г.Казань　　　　　№ 379-осн

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең коммерциясез оешмалар белән идарә итүдә бер кеше кулындагы башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә катнашуга яисә аларның коллегиаль идарә органнары составына керүгә эшкә яллаучы вәкиленнән рөхсәт алу тәртибен раслау турында

«Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы федераль законның 17 статьясының 1 өлешендәге 3 пунктына нигезләнеп, б о е р ы к　б и р ә м:

1. Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең коммерциясез оешмалар белән идарә итүдә бер кеше кулындагы башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә катнашуга яисә аларның коллегиаль идарә органнары составына керүгә эшкә яллаучы вәкиленнән рөхсәт алу тәртибен (кушымтада бирелә) расларга.

2. «Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренә коммерциясез оешмалар белән идарә итүдә бер кеше кулындагы башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә катнашуга яисә аларның коллегиаль идарә органнары составына керүгә эшкә яллаучы вәкиленең ризалык бирү тәртибе турында» 2017 елның 17 июлендәге 540-осн номерлы боерыкны көчен югалткан дип танырга.

Министр　　　　　　　　　　　　　　　　　　Р.Ә. Кузюров

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының 2019 елның 23.04.2019 № 379-осн боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең коммерциясез оешмалар белән идарә итүдә бер кеше кулындагы башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә катнашуга яисә аларның коллегиаль идарә органнары составына керүгә эшкә яллаучы вәкиленнән рөхсәт алу тәртибе

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең (алга таба – граждан хезмәткәрләре) иҗтимагый оешмага (сәяси партиягә, һөнәри берлек органына, шул исәптән Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының һөнәри оешмасының сайланма органына идарә итүдә катнашудан тыш), торак, торак-төзелеш кооперативына яки гараж кооперативына, яисә күчемсез мөлкәт милекчеләре ширкәтенә бер кулдагы башкарма орган сыйфатында яисә мондый оешманың коллегиаль идарә органы составына керү юлы белән (съезд (конференция) яки гомуми җыелыштан гайре) идарә итүдә түләүсез нигездә катнашуга эшкә яллаучы вәкиле булып торучы Татарстан Республикасы урман хуҗалыгы министрыннан рөхсәт алу процедурасын билгели.

2. Граждан хезмәткәрләренең түләүсез нигездә бер кулдагы башкарма орган сыйфатында коммерциясез оешмага идарә итүдә катнашуы яки аларның коллегиаль идарә органнары составына керүе мәнфәгатьләр каршылыгына яки вазыйфаи бурычларны үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгы барлыкка килү ихтималын китереп чыгармаска тиеш.

3. Түләүсез нигездә бер кулдагы башкарма орган сыйфатында коммерциясез оешмага идарә итүдә катнашуга яки аларның коллегиаль идарә органнары составына керүгә рөхсәт бирү турында гариза (алга таба – гариза) язмача рәвештә 1 нче кушымтага туры китереп төзелә.

4. Граждан хезмәткәрләре гаризаны Татарстан Республикасы урман хуҗалыгы министры (алга таба – министр) исеменә ниятләнгән түләүсез нигездә бер кулдагы башкарма орган сыйфатында коммерциясез оешмага идарә итүдә катнашу яки аларның коллегиаль идарә органнары составына керү башланганчыга кадәр коррупциячел һәм башка төр хокук бозуларны профилактикалау өчен җаваплы затка (алга таба – Җаваплы зат) тапшыралар.

5. Гариза килгән көнендә Җаваплы башкаручы тарафыннан, 2 нче кушымтага туры китереп, гаризаларны теркәү журналында теркәлә.

Гаризаның күчермәсе, теркәүгә алу турындагы тамга белән, граждан хезмәткәренә гаризаларны теркәү журналында кул куйдыртып бирелә яисә, кулга тапшыру турында белдереп, почта юлламасы ярдәмендә җибәрелә.

6. Җаваплы башкаручы гаризаны беренчел карый һәм граждан хезмәткәренең

түләүсез нигездә бер кулдагы башкарма орган сыйфатында коммерциясез оешмага идарә итүдә катнашуының яки аларның коллегиаль идарә органнары составына керүенең мөмкин булуы (мөмкин булмавы) турында нигезләнгән бәяләмә (алга таба – нигезләнгән бәяләмә) әзерләүне гамәлгә ашыра.

Нигезләнгән бәяләмәне әзерләгәндә Җаваплы зат, гариза тапшыручы граждан хезмәткәренең ризалыгы белән, аның белән әңгәмә уздырырга һәм аннан язмача аңлатмалар алырга мөмкин.

7. Нигезләнгән бәяләмәдә түбәндәгеләр булырга тиеш:

а) граждан хезмәткәренең коммерциясез оешмага карата кадрлар, оештыру-техник, финанс, матди-техник яки башка мәсьәләләрдә карарлар, шул исәптән әлеге коммерциясез оешма тарафыннан билгеле бер эшчәнлекне һәм (яки) аерым эшчәнлекләрне гамәлгә ашыруга рөхсәтләр (лицензияләр) бирүгә бәйле карарларны кабул итү буенча вәкаләтләренә анализ;

б) граждан хезмәткәренең дәүләт граждан хезмәте турында һәм коррупциягә каршы көрәш турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән, вазыйфаи бурычларны намуслы үтәүне тәэмин итә торган тыюларны, чикләүләрне һәм бурычларны үтәвенә анализ.

8. Гариза һәм нигезләнгән бәяләмә гариза теркәлгәннән соң биш эш көне эчендә карар кабул итү өчен эшкә яллаучы вәкиленә җибәрелә.

9. Гаризаны һәм нигезләнгән бәяләмәне карау нәтиҗәләре буенча эшкә яллаучы вәкиле түбәндәге карарларның берсен чыгара:

а) граждан хезмәткәренә түләүсез нигездә бер кулдагы башкарма орган сыйфатында коммерциясез оешмага идарә итүдә катнашуга яки аларның коллегиаль идарә органнары составына керүгә рөхсәт итәргә;

б) түләүсез нигездә бер кулдагы башкарма орган сыйфатында коммерциясез оешмага идарә итүдә катнашуга яки аларның коллегиаль идарә органнары составына керүгә рөхсәт бирүдән баш тартырга;

в) гаризаны һәм нигезләнгән бәяләмәне карау өчен Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу буенча комиссиясенә (алга таба – Комиссия) гаризаны тапшырган граждан хезмәткәрендә, аның түләүсез нигездә бер кулдагы башкарма орган сыйфатында коммерциясез оешмага идарә итүдә катнашуы яки аларның коллегиаль идарә органнары составына керүе очрагында, шәхси кызыксынучанлык һәм мәнфәгатьләр каршылыгы барлыкка килү ихтималының булуы предметына карау өчен тапшырыла.

Комиссия утырышында гаризаны һәм нигезләнгән бәяләмәне карау нәтиҗәләре буенча эшкә яллаучының вәкиле граждан хезмәткәренә түләүсез нигездә бер кулдагы башкарма орган сыйфатында коммерциясез оешмага идарә итүдә катнашуга яки аларның коллегиаль идарә органнары составына керүгә рөхсәт бирү (рөхсәт бирмәү) турында карар кабул итә.

10. Җаваплы зат эшкә яллаучы вәкиле гаризаны, нигезләнгән бәяләмәне карау нәтиҗәләре буенча карар кабул иткән вакыттан башлап өч эш көне эчендә граждан

хезмәткәренә кул куйдыртып язмача формада эшкә яллаучы вәкиле тарафыннан кабул ителгән карар турында хәбәр итә яки эшкә яллаучы тарафыннан кабул ителгән карар турындагы мәгълүмат дәүләт граждан хезмәткәренә, кулга тапшыру турында белдереп, почта юлламасы ярдәмендә җибәрелә.

11. Гариза, нигезләнгән бәяләмә һәм гаризаны карауга бәйле башка материаллар (алар булган очракта) граждан хезмәткәренең шәхси эшенә теркәлә.

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең коммерциясез оешмалар белән идарә итүдә бер кеше кулындагы башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә катнашуга яисә аларның коллегиаль идарә органнары составына керүгә эшкә яллаучы вәкиленнән рөхсәт алу тәртибенә 1 нче кушымта

Татарстан Республикасы урман хуҗалыгы министрына

_____________________________________
(инициаллары, фамилиясе)
кемнән _______________________________
_____________________________________
(вазыйфа атылышы)
_____________________________________
(структур бүлекчә)
_____________________________________
(фамилиясе, исеме һәм атасының исеме (булган очракта))

Түләүсез нигездә бер кулдагы башкарма орган сыйфатында коммерциясез оешмага идарә итүдә катнашу яки аларның коллегиаль идарә органнары составына керү турында
ГАРИЗА

«Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы федераль законның 17 статьясының 1 өлешендәге 3 пункты нигезендә миңа түләүсез нигездә коммерциясез оешмага идарә итүдә

________________________________________________________________________
(торак, торак-төзелеш яки гараж кооперативының, йә күчемсез мөлкәт милекчеләре ширкәтенең
________________________________________________________________________
атамасын, адресын, эшчәнлек төрләрен күрсәтергә)

бер кулдагы башкарма орган сыйфатында катнашуга яки аның коллегиаль идарә органы составына керергә (кирәклесе астына сызарга) рөхсәт бирүне сорыйм.

Күрсәтелгән эшчәнлекне үтәү хезмәттән буш вакытта гамәлгә ашырылачак һәм мәнфәгатьләр каршылыгы барлыкка килүгә яисә вазыйфаи бурычларны үтәгәндә

мәнфәгатьләр каршылыгы барлыкка килү ихтималына китереп чыгармаячак.

________________ _____________________________ «___»_________20__ел.
(имза) (тулы имза)

Танышып чыктым

__________________________________________________________________________
(Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының структур бүлекчәсе
__________________________________________________________________________
җитәкчесенең граждан хезмәткәре түләүсез нигездә коммерциясез оешмага идарә итүдә
__________________________________________________________________________
бер кулдагы башкарма орган сыйфатында яки аның коллегиаль идарә органы составына керү
__________________________________________________________________________
юлы белән катнашуы очрагында вазыйфаи бурычларны үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгы
__________________________________________________________________________
барлыкка килү ихтималы турындагы фикере)
__________________________________________________________________________

__________________________________________________________________________
(Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының структур бүлекчә җитәкчесенең вазыйфа аталышы, фамилиясе, исеме, ата исеме (булган очракта))

_________________________ __________________
(имза) (дата)

Гаризаларны теркәү журналында теркәлү номеры
__________________________________________________

Гаризаны теркәү датасы «____»_____________ 20 __ ел.

_____________________________________________ _________________________
(гаризаны теркәүче затның имзасы) (тулы имза)

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең коммерциясез оешмалар белән идарә итүдә бер кеше кулындагы башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә катнашуга яисә аларның коллегиаль идарә органнары составына керүгә эшкә яллаучы вәкиленнән рөхсәт алу тәртибенә 2 нче кушымта

Түләүсез нигездә бер кулдагы башкарма орган сыйфатында коммерциясез оешмага идарә итүдә катнашуга яки аларның коллегиаль идарә органнары составына керүгә рөхсәт бирү турында гаризаларны теркәү журналы

| № п/п (гаризаны теркәү номеры) | Гари-за ны теркәү-гә алу датасы | Гаризаның кыскача эчтәлеге | Гариза тапшыручы затның фамилиясе, исеме, ата исеме (булган очракта), вазыйфа аталышы | Гаризаны кабул итүче затның фамилиясе, исеме, ата исеме (булган очракта), вазыйфа аталышы | Гаризаның күчермәсен алу турында (күчермәне алды, гариза тапшыручы затның имзасы) яки гариза күчермәсен почта элемтәсе ярдәмендә җибәрү турында (адресын күрсәтергә) тамга | Кабул ителгән карар турында тамга |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
| | | | | | | |